КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 4 март г.Казань № 161

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 4 март, 161 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – сайлап алуда катнашучы, субсидия) бирү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Субсидия бирү максаты – Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укыту белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

3. Бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен башкаручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган).

Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен тиешле финанс елына субсидияләр бирүгә бюджет акчасын алучы буларак вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Субсидия бирү ысулы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре:

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча

һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуны оештыруга һәм үткәрүгә бәйле персонал хезмәте өчен түләү;

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуны оештыру һәм үткәрү белән бәйле төзелгән кайтартулар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, шул исәптән элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре һәм башка шартнамәләр буенча түләү;

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча һөнәри укытуны оештыру һәм үткәрү белән бәйле исәпләнгән, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнә торган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр.

5. Субсидия күләме ($С_р$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_р = Р_1 + Р_2 + Р_3,$$

монда:

$Р_1$, $Р_{2,}$ – әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы икенче, өченче абзацларда күрсәтелгән юнәлешләр буенча фактта башкарылган чыгымнар, алар вәкаләтле орган тарафыннан бердәй (бертөрле) эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә, сум;

$Р_3$ – әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән юнәлеш буенча салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган чыгымнар, сум.

6. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын уңышлы үзләштергән укучыларның саны 2026 елның 31 декабренә кадәр кимендә 1 185 кеше тәшкил итә;

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программаларын уңышлы үзләштергән укучыларның саны 2027 елның 1 сентябренә кадәр иң күбе 845 кеше тәшкил итә;

Субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре һәм аларга ирешү срогы субсидия бирү турындагы килешүдә (алга таба – килешү) билгеләнә.

7. Субсидия турында мәгълүмат субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә

«Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) урнаштырыла.

8. Субсидия алучыны сайлап алу вәкаләтле орган тарафыннан, сайлап алуда катнашучының сайлап алу критерийларына туры килү-килмәвенә һәм заявкаларның керү тәртибенә карап, сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән тәкъдимнәр (заявкалар) сорап алу юлы белән үткәрелә.

Сайлап алу «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон рәвештә документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

укучыларның һөнәри үзбилгеләнешенә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсе булу, Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында һөнәри белем бирүне популярлаштыру;

һөнәри укытуның мәгариф программаларын гамәлгә ашыру буенча, өстәмә белем бирүнең ярдәмче төрләре буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булу;

заявка бирү датасына кимендә алты ай һөнәри укытуны оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыру;

субсидия алучы Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли.

10. Сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты,

шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмау;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмау;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмау.

Сайлап алуда катнашучының әлеге пункт нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, гариза бирүченең әлеге пунктта билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турындагы билгеләрне электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

11. Заявкаларны сайлап алуны үткәрү сроклары, кабул итү сроклары, заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты вәкаләтле орган боерыгы белән раслана.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана,

«Электрон бюджет» системасында урнаштырыла, шулай ук бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу үткәрелә башлаган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

Сайлап алуны үткәрү турында белдерү түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән ким булмаган сайлап алуны үткәрү сроклары (заявкалар бирү (кабул итү) башлану (тәмамлану) датасы һәм вакыты);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 18 – 23 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» челтәрендәге бердәм порталында һәм вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

12. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 11 пунктында билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкаларны бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

13. Сайлап алуны үткәрүгә үзгәреш кертү турында белдерү «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны үткәрүгә үзгәреш кертү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны үткәрмәү сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны уздырмау очрагы – әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максат өчен вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире алу.

Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучыларга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздырмау турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алу бердәм порталда сайлап алуны үткәрмәү турында белдерү урнаштырылган көннән уздырылмаячак дип санала.

Әлеге пунктның алтынчы абзацы нигезендә сайлап алуны үткәрмәү срогы тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзегәнгә кадәр вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә җиңеп булмый торган көч шартлары барлыкка килгән очракта гына сайлап алу үткәрелмәскә мөмкин.

14. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән срокларда заявканы «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә төзи һәм бирә һәм «Электрон бюджет» системасына документларның электрон күчермәләрен (сканлаштыру юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр кертү турында документлар күчермәләре;

сайлап алуда катнашучыны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык яисә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында һөнәри белем бирүне популярлаштыруга, укучыларның һөнәри билгеләнешенә юнәлдерелгән чараларны оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыруны һәм заявка бирү датасына кимендә алты ай һөнәри белем бирүне оештыруны һәм үткәрүне раслый торган документлар;

вәкаләтле орган боерыгы белән расланган форма буенча эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын һөнәри укытуга бәйле чаралар планы.

Әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән документлар сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылмаган булса, вәкаләтле орган аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Заявкага сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Заявкадагы мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре барлык документны йә аның өлешен карау мәгълүматны карауны һәркем файдалана алырлык программа белән тәэмин итү чаралары белән карау мөмкинлеген тәэмин итә торган киң таралган ачык форматларга ия булырга тиеш һәм махсус программа яисә технологик чаралардан башка аларның эчтәлеге белән танышуны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яисә саклаган булырга тиеш түгел.

15. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирелгән дата итеп сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкага, «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры бирелеп, имза куелган көн санала.

Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

юридик затның адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучы җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификация номеры, вазыйфасы);

сайлап алуда катнашучы оешманың гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге;

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүгә имза куярга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) сайлап алуда катнашучының сайлап алуны уздыру турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган мәгълүмат һәм документлар;

в) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

г) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәсе,

соратып алына торган субсидия күләме.

16. Заявканы теркәгәннән соң аңа үзгәрешләр кертү һәм эшләп бетерүгә кире кайтару (әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы икенче абзацында каралган очрактан тыш) рөхсәт ителми.

Сайлап алуда катнашучы заявканы «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны уздыру тәмамлануга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булса, сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән тәртип кебек үк тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Сайлауда катнашучылар, бердәм порталда сайлау үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән һәм заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында тиешле мөрәҗәгатьләр булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында рәсми сораулар җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган, әлеге пунктта күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма заявкалар бирүне төгәлләү көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

18. Вәкаләтле орган заявкаларны карап тикшерү максатларында комиссия формалаштыра, аңа вәкаләтле орган каршындагы Иҗтимагый совет әгъзалары да кертелә. Комиссиянең составы, комиссиянең эш тәртибе вәкаләтле органның боерыгы белән раслана.

Комиссия комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары составында төзелә.

Комиссия утырышы вәкаләтле дип санала, әгәр анда әгъзаларының кимендә яртысы (комиссия рәисен яки ул булмаганда комиссия рәисе урынбасарын кертеп) катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия утырышында комиссия рәисе булмаган очракта, комиссия рәисе вәкаләтләрен комиссия рәисе урынбасары гамәлгә ашыра.

Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелеге тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Заявкаларны карап тикшерү комиссия тарафыннан «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карап тикшерү өчен вәкаләтле органга һәм комиссиягә керү мөмкинлеге ачылган көннән соң килә торган 15 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле органга һәм комиссиягә «Электрон бюджет» системасына керү

мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

19. Комиссия сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килгән бер эш көненнән дә соңга калмыйча заявкаларны ачу беркетмәсен имзалый, алар сайлауда катнашу өчен килгән заявкалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) заявканы теркәү номеры;

б) заявка керү датасы һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

г) юридик затның адресы;

д) сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

20. Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм заявканы кабул итмәү өчен нигезләр булмаганда, ул дөрес дип танылa.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә заявканың туры килүе-килмәве хакында карар комиссия тарафыннан сайлап алуда катнашучы заявка белән бергә биргән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көндә кабул ителә.

21. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлауда катнашучының сайлап алуны уздыру турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның һәм (яки) заявканың сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

22. Сайлап алу түбәндәге очракларда булмаган дип танылa:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

23. Кергән заявкалар аларның чиратыннан чыгып рангларга бүленә.

Комиссия сайлап алуда җиңүчене, сайлап алу таләпләренә һәм кергән заявкаларны рангларга бүлү нәтиҗәләренә туры килү-килмәүдән чыгып, сайлап алу турында белдерүдә күрсәтелгән, бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә билгели.

24. Сайлап алуны төгәлләү һәм җиңүчене ачыклау максатларында сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисе һәм комиссиясе әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда аңа кул куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла һәм, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14нче календарь көннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенә түбәндәге белешмәләр керә:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктның беренче – алтынчы абзацларында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

25. Әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган субсидия күләмен сайлап алу йомгаклары беркетмәсендә күрсәткәндә ул сораган субсидия күләме әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибенә туры килмәгән очракта комиссия мондый сайлауда катнашучы өчен каралган субсидия күләмен төзәтергә мөмкин, әмма ул заявкада күрсәтелгән күләмнән югарырак булмаска тиеш.

26. Вәкаләтле орган сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе «Электрон бюджет» системасында урнаштырылган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул вәкаләтле орган боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

27. Субсидия бирү, сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң 20 эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле орган һәм сайлап алуда җиңүче арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләгән бертип форма нигезендә төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имза куела.

Әгәр сайлап алуда җиңүче тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта килешүгә кул куелмаган булса, ул килешү төзүдән читләшкән дип санала.

Вәкаләтле органга элегрәк җиткерелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта, килешүгә килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт кертелә.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.

Вәкаләтле орган, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

28. Кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә субсидия алучы үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

29. Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

30. Вәкаләтле орган, сайлап алуда җиңүченең сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү факты ачыкланган очракта яисә сайлап алуда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта,

сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

31. Вәкаләтле орган, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан Россия кредит оешмасында субсидия алучыларга ачылган счетларга күчерә.

32. Субсидия алучы субсидияләр керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, шулай ук субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган формалар буенча төзелгән финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның икенче абзацында каралган, субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны «Электрон бюджет» системасы аша алар бирелгән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча тикшерә.

Субсидия алучы бирә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрдән максатчан файдаланылмау өчен законнар нигезендә җавап бирә.

33. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган яки субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат бирү факты, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, субсидия Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Вәкаләтле орган әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган вакыйгалар ачыкланган көннән алып 30 календарь көннән артмаган срок эчендә субсидия алучыга субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән әлеге таләп алынган көннән 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.

34. Агымдагы елның 31 декабренә карата субсидия акчасының файдаланылмый калган өлешләре субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр килешүдә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

35. Әлеге Тәртипнең 33 һәм 34 пунктларында күрсәтелгән субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару сроклары бозылган очракларда, вәкаләтле орган субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

36. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән әлеге Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

37. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау тәртибе нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

38. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

___